**ГЛАВА ЕГОРЬЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422621д. Каипы,
ул. Центральная, д.50
тел: 3-36-19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЕГОРЬЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**
422621Каипы авылы,
Эзек урамы, 50 нчы йорт,
тел: 3-36-19

**2021елның 8 ноябре** **11 номер**

# КАРАР

## «FORESTPARKFAMILY» коттедж поселогы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 11 декабрендәге 96-РС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 61-РС номерлы үзгәрешләр кертелгән карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә таянып, территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын аерып чыгару, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, карар бирәм:

1. «FORESTPARKFAMILY» коттедж поселогы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә (кадастр номерлары 16:24 070801:2278, 16:24:070801:2277, 16:24 070801:2276, 16:24 070801:2275булган җир кишәрлекләре);

2. Гавами тыңлаулар уздыру чорын - кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итү мизгеленнән алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр дип билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы бер айдан ким булмаска һәм ике айдан артмаска тиеш.;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Башкарма комитетына:

3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган гавами тыңлауларның башлануы турында хәбәр әзерләргә;

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 14 эш көне эчендә әлеге карарның 3.1 п. күрсәтелгән хәбәрнамәне җирлек уставында билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.3. Әлеге карарның 2 п. пунктында күрсәтелгән чорда гавами тыңлаулар уздырырга;

3.4. Территорияне планлаштыру һәм межалау проектын, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне, ахыргы карар кабул итү өчен, гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлегенең рәсми сайтында https://laishevo.tatarstan.ru/egorevskoe-selskoe-poselenie.htm адресы буенча норматив - хокукый документлар бүлегендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Егорьево авыл җирлеге Советы рәисе Р.Җ.Хәмидуллин**